**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Ш.Марджани, дом 6

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Ш.Мәрҗани урамы, 6 нчы йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

“12” декабря 2025г.№ 4

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Кышлау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планы проектын карау буенча гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү.**

Әлеге мәгълүмат белән Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Кышлау авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планы проектын (алга таба – проект) карау буенча гавами тыңлаулар башлануы турында хәбәр итәбез.

**Проектка мәгълүмати материаллар исемлеге:**
1) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышлау авыл җирлеге генераль планы проекты:
- текст формасында нигезләү материаллары;
- текст формасындагы нигезләү материаллары (ООС ГОиЧС)
- территориаль планлаштыру турындагы нигезләмә:
- табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыгу куркынычы янаган территорияләр, Гражданнар оборонасы чаралары картасы ;
- торак пунктларның чикләре картасы;
- зоуит картасы (проект тәкъдиме);
- зоуит картасы (гамәлдәге хәл);
- инженерлык инфраструктурасы картасы;
- җирле әһәмияттәге объектларны планлаштырып урнаштыру картасы;
- җирлек территориясеннән заманча файдалану картасы;
- функциональ зоналар картасы;
- торак пунктларның чикләре турында белешмәләр.

**Проект буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе һәм сроклары:**
Проект буенча гавами тыңлаулар 2025 елның 12 декабреннән 19 декабренә кадәр вакыт аралыгында уздырыла.
Гавами тыңлаулар үткәрү процедурасына түбәндәге этаплар керә:
- гавами тыңлаулар башлану турында хәбәр итү;
- проектны һәм аңа мәгълүмати материалларны рәсми сайтка урнаштыру һәм мондый проект экспозицияләрен ачу;
- проект экспозицияләрен үткәрү;
- гавами тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын үткәрү;
- гавами тыңлаулар беркетмәсен әзерләү һәм рәсмиләштерү;
- гавами тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләү һәм бастырып чыгару.

**Гавами тыңлауларда катнашучылар даирәсе:**

Проект буенча гавами тыңлауларда катнашучылар булып түбәндәгеләр тора:
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышлау авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче гражданнар;
- Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышклы авыл җирлеге чикләрендәге җир кишәрлекләренең һәм (яисә) аларда урнашкан капиталь төзелеш объектларының хокук ияләре,
- күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының бер өлеше булган урыннарның хокук ияләре.

**Гавами тыңлаулар үткәрелә торган территория**: Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Кышлау авыл җирлеге.

**Проект экспозициясен ачу урыны һәм датасы:**
- Кышлау авылы, Татарстан урамы, 7 йорт адресы буенча урнашкан Кышлау авылы мәдәният йортында 2025 елның 15 декабрендә;
- Кызыл Утар авылы, Ленин урамы, 4 йорт адресы буенча урнашкан Кызыл Утар авылы клубында 2025 елның 15 декабрендә;
- Олы Әтнә авылы, Ш. Мәрҗани ур., 6 йорт адресы буенча урнашкан Әтнә районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге кабинеты, 2025 елның 12 декабреннән.

**Проект экспозицияләрен үткәрү сроклары:**
2025 елның 12 декабреннән – 2025 елның 19 декабренә кадәр вакыт аралыгында.

**Экспозицияләрне карарга мөмкин булган көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат:** дүшәмбе-җомга 8:00 сәгатьтән 11:00 сәгатькә кадәр, 13:00 сәгатьтән 17:00 сәгатькә кадәр.

**Гавами тыңлауларда катнашучыларның проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү тәртибе, сроклары һәм рәвеше:**
2025 елның 12 декабреннән 2025 елның 19 декабренә кадәр Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (алга таба – РФ ГрК) $5^1$ маддәсенең 12 өлеше нигезендә узган гавами тыңлауларда катнашучылар проектка кагылышлы тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертергә хокуклы.:
- рәсми сайт аша;
- язма рәвештә яисә электрон документ рәвешендә Татарстан Республикасы Әтнә район башкарма комитетының гавами тыңлауларны оештыручысы адресына: 422750, Татарстан Республикасы, Әтнә районы, Олы Әтнә авылы, Ш.Мәрҗани урамы, 6 йорт, тел. (84369) 2-10-13 (9.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр);
- гавами тыңлауларда каралырга тиешле проектның экспозициягә килүчеләрне исәпкә алу журналына язу юлы белән: 422751, Татарстан Республикасы, Әтнә районы, Кышлау авылы, Татарстан ур., 7 йорт (9.00 дән 17.00 гә кадәр).

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше Кодексының $5^1$ статьясының 12 өлеше нигезендә идентификацияләнгән гавами тыңлауларда катнашучылар гавами

тыңлауларда катнашучыларның җыелышларын уздыру барышында язма рәвештә яки телдән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертү хокукына ия.

**Гавами тыңлауларда катнашучылар җыелышын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында мәгълүмат:**
Проект буенча гавами тыңлауларны 2025 елның 19 декабрендә уздырырга:
- Кышлау авылында 10.00 сәгатьтә, Кышлау авылы, Татарстан ур., 7 йорт адресы буенча урнашкан Кышлау авылы мәдәният йортында;
- Кызыл Утар авылында 11.00 сәгатьтә, Кызыл Утар авылы, Ленин ур., 4 йорт адресы буенча урнашкан Кызыл Утар авыл клубында.;
- Яңа Өҗем авылында 12.00 сәгатьтә Вахитов урамындагы 13 нче йорт янында.

**Гавами тыңлауларда каралырга тиешле проект урнаштырылачак рәсми сайт турында мәгълүмат:**
Проект Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылачак (atnya.tatarstan.ru) 2025 елның 12декабреннән «Район турында>Җирлекләр> Кышлау авыл җирлеге> Территориаль планлаштыру> Авыл җирлеген генераль планлаштыру документлары» битендә (https://atnya.tatarstan.ru/territorialnoe-planirovanie-426328.htm) урнаштырылачак.

**Әлеге хәбәрнамәне** Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматләр рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында (atnya.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Әтнә районы
башкарма комитеты җитәкчесе А. Ф. Каюмов